# TUKAY ŞİİRLERİNDE DİNİ MOTİFLER[*]

Yard. Doç. Dr. Çulpan ZARİPOVA  ÇETİN

Muğla Üniversitesi Fen-Edebiyat Fakültesi
Çağdaş Türk Lehçeleri ve Edebiyatları Bölümü

**Ч. А. ЗАРИПОВА**
**(Казан)**

## ТУКАЙ ШИГЪРИЯТЕНДӘ ДИНИ МОТИВЛАР ЧАГЫЛЫШЫ

Коръән мөселман халыкларының әдәбиятына гына түгел, бөтен дөнья әдәбиятына да нык тәэсир итүче чыганак булып торган. Коръәннең аерым сүрәләрен, шигырьләрен стильләштерү, андагы мотивларга шигъри җаваплар күп кенә Көнбатыш Европа һәм рус язучылары әсәрләрендә дә байтак (Мәсәлән, Вольтерның, "Фанатчылык яки Мөхәммәт Пәйгамбәр"е, Монтескьеның "Фарсы хатлары", Гетенең "Көнбатыш-Көнчыгыш диваны", Г. Гейне шигырьләре, Пушкинның "Коръәнгә нәзыйрә"се, Лермонтов, Фет һәм башка шагыйрьләр шигырьләре). Гомумән, Көнчыгыш белән кызыксыну, мөселманнарның изге китабы Коръәнгә мөрәҗәгать итү — романтизмга хас сыйфат.

[*] Bu makale Tatar Türkçesi'nde yazılmış olup" Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары." /Tukay ve XX. Yüzyıl Medeniyeti. Şairin 110. Yıldönümü Nedeni ile Düzenlenen Uluslararası Sempozyum Bildirileri. Kazan, 1997, s. 129–135.) adlı kitapta yayınlanmıştır.

Бөтен мөселман Кынчыгыш әдәбияты Коръәннән цитаталар, андагы образлар, сюжетлар белән сугарылган. Татар, гомөмән төрки, әдәбиятына да изге китапның тәэсире зур. Коръән татар әдәбиятына төп юнәлеш биргән, күп кенә шагыйрь-язучыларның дөньяны күзаллавында мөһим фактор булып торган. Үзләренең шигъри — проза әсәрләрендә татар шагыйрьләре, язучылары Коръәннең сүрәләрен, аятьләрен, хәдисләр кулланганнар. Бу хакта галимебез Хатип Миңнеголов та язып чыкты [1].

Коръән XX йөз башы татар шагыйрьләре өчен дә илһам чыганагы булып торган. Безне Г. Тукай иҗатындагы дини мотивлар кызыксындыра, ни дәрәҗәдә Коръән китабы тәэсирләндергән шагыйрьне. Бу хакта мәтбугатта әдәбият белгечләре Н. Исмәгыйль, М. Җәмәлиева, Ә. Еники язып чыкканнар иде инде. Ләкин без дини мотивларны аерым, Г. Тукай иҗатында гына карап калмыйбыз. Шул чор башка шагыйрьләр иҗатына да хас булган Коръәнгә мөрәҗәгать итү. Г. Тукайның замандашлары, башка олугъ шагыйрьләребез Сәгыйть Рәмиев, Нәҗип Думави, Сәгыйть Сүнчәләй, Шәехзадә Бабичларны атап үтәсе килә бу рәттән. Ләкин беренче нәүбәттә дини мотивлар чагылышын Тукай иҗатында карап үтик.

Н. Исмәгыйль хаклы, Тукай бөтен тамырлары белән борынгы татар әдәбиятына, Көнчыгыш әдәбиянтына һәм тулаем ислам мәдәниятенә тоташа [2]. Ә ислам мәдәнияте иң беренче чиратта Коръән-Кәрим җирлегеннән үсеп чыккан. Тукай Аллаҗны бар вә бер дип таный, Коръәнгә ихтирамы чиксез зур:

Гомернең иң читен, җайсыз, уңайсыз бер минутында,
Әгәр янсам каты хәсрәт вә кайгының мин утында,
Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗаиб сүрә Коръәннән,—
Газаплар мәгънәви бер кул илән алынадыр җаннан.
*("Тәэссер", 1908)*

Идеология таләпләреннән чыгып бездә Тукайны төрле вакытта төрлечә бәяләү аз булмады. Ләкин без турыдан-туры аның шигырьләренә мөрәҗәгать итсәк — аларның күбесен Тукай Аллага ианып, Аллага сыенып язганлыгында шик калмый. 1905 елда язылган (шагыйрьгә нибары 19 яшь!) "Гөлүмең бакчасында..." шигырендә Тукай татарларның язмышын кайгыртып:

Татарларның бөеклеге, даны сигез кат күкләргә китсен;
Мәңге, һәрвакыт бу милләтне ходаем бәхетле итсен,—

ди. Ә бу шигырьнең дәвамы булып торган "Чөнанча бездә..." шигырендә Тукай барча кешеләрне үзара якынаерга, дуслашырга чакырганда да Алла образын куллана:

Барчагыз Алла җебенә ныклап тотыныгыз.

Алла якынайтучы, кешеләрне берләштерүче буларак кабул ителә Тукай тарафыннан. Бу шигырьдән күренгәнчә, Тукай үзенең исеменең мәгънәсенә, исеме белән үк Аллага якын булуына басым ясый:

Исемем Габдулла — алла бәндәсемен.

Тукайның "Алла гыйшкына" дигән шигыре дә кешеләрне дөрес юлдан барырга, гыйлем алырга, белгән һөнәрләр белән генә

канәгатьләнмәскә, тату яшәргә, милләтне күтәрергә чакыра... "...алла яратсын өчен!"

Алла, тәңре сүзләрен кулланганда Тукай Аллага энләшкәндә Коръән әйтә торган эпитетларны да читтә калдырмый:

> Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
> Бәйләмеш бу җиргә безне тәңребез (гыйззе вә җәл),—
> *("Китмибез", 1907)*

монда ахырдан ул "кодрәтле вә шанлы" дигән (гыйззе вә җәл) эпитетларны китерә.

Тукайның аерым шигырьләре тулаем Коръән аятьләренә, сүрәләренә багышланган: "Мигъраҗ", шигыре Коръәндәге 17 нче сүрәне эченә алган (Мөхәммәт пәйгамбәрнең Мәккәдән Коддәскә сәфәре, Әл-Әкъса мәчете гөмбәзеннән күккә ашуы турында). Тукай кечкенәдән үк пәйгамбәребез тарихын укып үскән, күп кенә сюжетлар аны илһамландырган. Бу хакта "Туган авыл" шигырендә укый алабыз.

Тукайның "Кадер киче" дип исемләнгән әсәре дә турыдан-туры Коръәнгә барып тоташа, ул андагы "Кадер" дип аталган 97 нче сүрәне шагыйрәнә тасвирлап биргән. "Кадер кич" исемле тагын бер шигыре бар Тукайның. Аны галим М. Гайнетдинов "Тукайның адашкан шигырьләре" дигән мәкаләсендә китерә[3]. Г. Тукайның җыентыкларында ул шигырь юк. Бу "Кадер кич" әсере шулай ук Коръән аятенең тулаем шигъри сүрәсе булып тора. Бер Кадер кич Тукайны ике шигырь язарга илһамландырсын әле!..

Тукай күп кенә шигырьләрендә Алланың вәгъдәләренә дә туктальш китә, чын күңелдән ышанып, аларга таянып яши, башкаларны да юата. Мәсәлән, "Борадәранә нәсихәт" (1906) шигырендә:

> Бераүнең уйларын икенче бераү бикләп куя алмас;
> Теләгендә нык торучыны беркем өметсез итә алмас.
> Тәңребезнең бергә кушуы: "Өметсезләнмәгез",—

ди. "Юаныч" шигырендә дә Тукай нәкъ шушы Коръәндә Алла сүзе итеп бирелгән "Ля тәйәсү!" (Өметсезләнмәгез!) дигән сүзләрне китерә.

"Тәрбиятел әтфаль "гә шигырендә үз-үзен һәм атасын бер мөселман баласы болай юата:

> Мин ышанам ки: ходай сине җинаятьчеләргә бирмәс,
> Дин саклаучыларга "Куркыныч юк..." дигән вәгъдәсе бар.

Монда алланың Корьәндәге "Ля хәүфен галәйһим..." дигән сүзләре китерелә. "Шиһаб хәзрәт" шигырендә дә Тукай "Тәззәккәрү!" ("Искә алыгыз!"), "Тәфәккәрү!" ("Уйлагыз!") дигән Алла сүзләрен китерә.

Коръәннең 68 нче "Нүн" ("Каләм") сүрәсендә Алланың: "Каләм беләп ант итәм", дигән сүзләре бар. Бу иң нык, ышанычлы ант санала. Тукай бу афоризмны да бик оста, урынлы куллана белгән, язучыларның кадерен белергә чакырып, дәрәҗәләрен дин сүзләре белән расдый:

Язучылар диндә ныклыкка сәбәп,
Ике дөнья тәмугыннан котылуга чара.
Каләм — бөек, каләм — дәрәҗәле;
Ходайның телендә ант урынында ул.
*("Хәзерге халемезә даир", 1905)*

Каләм иярәренең язганнары, каләм тибрәтүләре өчен ни дәрәҗәдә җаваплы булуларын да күрсәтә ул бу юллар белән!

"Сөальләр" шигырендә Тукай күңелен сораулар биләп алган:

Әллә җәһәннәмнәр, тәмуглар да бу өтелгән тәндәме?
Әллә тәмуг уты чыннан да шагыйрь күңелендәме?,—

дип ачынып яза шагыйрь. Бу сорауларның җавабын бары тик Ходай гына бирә ала, дип саный ул:

Серләр ачучы! ач бу серне...,—

дип яза, Коръәндәге Алланы — "Кәшифел әсрар" (Серләр ачучы") дигән сүзләргә таянып.

"Көзге җилләр", "Могъҗиза", "Нәсихәт" шигырьләрендә пәйгамбәрләр Ибраһим вә Исмәгыйл, Хөзер Ильяс исемнәрен, дини сюжетларны тәэсирне көчәйтү өчен китерә. "Мөхәрриргә" шигырендә Тукай Гаяз Исхакыйны хәлиф Гомәр белән тиңли:

"Ул Гомәрдән курка шайтаннар" дигән төсле рәсүл,
Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя...

"Катиле нәфескә" әсәрендә исә Тукай үзен-үзе үтерүчегә мөрәҗәгать итеп, аның хаксыз, Алла алдында гөнаһлы булуын әйтә. Чөнки китап, ислам дине кешенең үз-үзенә кул салуын бик зур гөнаһ, зур җинаять итеп саный. Кешегә гомер Алла тарафыннан бирелә, һәм Алла гына ала ала ул гомерне кешедән. "Үкенеч" шигырендә әйтелә бу хакта:

Яшып ялгыз шулай күп еллар үткәч,
Сүнәр идем, ходайдан вәгъдә җиткәч.

Шагыйрьнең "...гә" (1908) шигыре дә бик кызыклы:

Күргәнең бармы әле Коръәндәге мәдхияни?
Ул синең васфеңдә: "ля шәркыйя, ля гарбия",— ди!

Күк китабының сине белгәнлегенә шаккатып,
Ул хәзер алган "Сабах"тан бер Каләмулла сатып.

Бу шигырьне Тукай сөйгән кызы Зәйтүнә Мәүлүдовага багышлап яза. Коръәндә "Зәйтүнәтен ля шәркыя ля гарбия" дигән сүзләр бар. Алланы сыйфатлаганда, изге китапта — "ул бар, әмма унда да түгел, сулда да түгел, алда да түгел, артта да түгел, аста да түгел, өстә дә түгел, ләкин бар", дигән мәгънәне аңлата алар. Коръәнне белгән кешегә бу шигырьнең Зәйтүнә исемле кызга багышланган икәнен белү бер дә кыен булмаган.

Хатын-кызның күз камыштырырлык матурлыгын сурәтләгәндә дә көчлерәк ышандыру өчен Тукай янә изге китаптагы образ-сюжетларны китерә:

Ул түнә, хәлсезләнә шул, очраса үз хурына,
Хәзрәти Муса тәхәммелсез тәҗалли нурына.
*("Гашыйк", 1909)*

Соңгы юллар дини мотивка ишарәли: Синайдагы Тур тавы башына Алла белән күрешергә килгән Муса пәйгамбәр тәңредән бер генә мәлгә йөзен күрсәтүен үтенә. "Күзең чагылып сукыраерсың", дип кисәтә Алла тавышы, ләкин бик үтенгәч, кыска бер мизгелгә йөзен ачса, Муса пәйгамбәр һушы китеп егыла.

Ә. Еники "Тукай шулай да ни өчен әле аллага инанган, аллага сыенган?" дигән сорауга җавапны шагыйрьнең язмышыннан—ятимлегеннән, ялгызлыгыннан, әҗәленә тигән авырудан эзләргә кирәктер дип таба [4]:

> Йә ходай, күрсәт диген, ушбу җиһанда якты юл;
> Ул — рәхимле; әткәң-әнкәңнәән дә күп шәфкатьле ул!,—

дип яза Тукай "Таян аллага" исемле шигырендә. Шагыйрь кәфергә тиңләүне дә, дәһли диюгә дә түзеп була, дип саный. Алла каргышы гына төшмәсен. Бар дөнья йөз чөерсә дә, ата-анасыз калсаң да, Алла гына үз мәрхәмәтеннән ташламасын:

> Чикмә хәсрәт! Кяфер дисен, динсез, алласыз дисен;
> Тик сиңа тәңренең каһәре генә килмәсен.
> *("Мөхәррирга", 1906)*.

Шагыйрь күңеле азан ишетеп ("Пар ат", "Кичке азан"), Коръән укып ("Тәэссер"), Аллага сыенып ("Күңел") яктыра, әсәрләнә. Сәйфи Кудаш Ә. Еникигә язан хатында Тукайның халык тарафыннан сөелүен турыдан-туры дини рухтагы шигырьләре белән дә бәйләп карый. Ә. Еникине генә түгел, безне дә ышандыра бу. Чыннан да, татар халкы гасырлар буе Аллага ышанып яшәгән, киләчәккә ышанычын да аллага багълаган. Тукай моны сиземләгән һәм халыкның иманына тугърылыклы булып калган. Дин тоткан, дини кагыйдәләрне үтеп барган, Коръәнне яттан белгән халыкка Тукай шигырьләре, дини мотивлар чагылдырган шигырьләре, әлбәттә, якын булган, үз булган.

Әмма Тукайның дингә мөнәсәбәте бер яклы гына түгел. Үз заманының иң алдынгы фикер иясе буларак, Тукай искелекне, динне кәсепкә әйләндерүне, наданлыкны, бозыклыкны тәнкыйтьләп чыгудан да баш тартмаган. Әмма бу динне, муллаларны тәнкыйть итү — ул әле Алладан ваз кичү түгел. Ә. Еники язуынча, "дини догмаларны тәнкыйть итеп тә, аллаларга ышанучылар тарихта аз булмаган". Монда әдибебез мисал итеп рус язучысы Лев Толстойны китерә. Ә мин икенче үзебезнең бөек татар шагыйребез Сәгыйть Рәмиевне атар идем. С. Рәмиев — гыйсьянчы, демоник шагыйрь буларак таныш безгә. Нәкъ менә бунтарь рухы белән кадерле, аермалы да башкалардан. Ләкин бит аны да Аллага фетнә белән чыгуы — ул әле шулай ук С. Рәмиевнең дә алласыз, динсез икәнен күрсәтми. Аңар да, поплар Л. Толстойны чиркәүдән аерган кебек, муллалар бәддога укып кала торган булганнар озын чәч йөртеп, гыйсьян күтәреп, хатын-кызны аллага тиңләве өчен. Сәгыйть Рәмиев Алланың барлыгына, берлегенә ышанып яшәгән шагыйрь. Ул Алланы инкарь итми, ә бәлки үзенең аннан канәгать булмавын белдерә. Мәсәлән, "Мин", "Мәҗид сүзе" шигырьләре. Ләкин инде "Алла", "Дога", "Тәсәлла" шигырьләрен китерсәк, без С. Рәмиевнең Алланы үзенең "мин"енең аерылгысыз, бердәнбер анлаучы кисәге итеп

күрүендә шикләнмибез. "Дога", "Тәсәлла" шигырьләрендә С. Рәмиев Аллага вәгъдәләрен исенә төшерә:

Әй илаһым, тот сүзеңне!
Үз сүзең: "Иннә кариб..."
*("Дога")*

Очрыймсың бәлаләргә, башым, очра!
Шөбһә юк, бер чыгарсың барып очна...
Җәнаб Алла вәгъдә биргән Коръәнендә:
"Ин мәгаль гөсри йосра, ин мәгаль гөсри йосра..."
*("Тәсәлла")*

Монда С. Рәмиев Коръәндәге "Мин якыныгыз, сорагыз, җавап бирермен...", "Авырлыклардан соң җиңеллекләр", дигән алла сүзләрен китерә. Г. Халит, күренекле галимебез, язуынча, С. Рәмиевнең күп кенә шигырьләре "коръәнләштерелгән". Өстә күрсәтеп киткән ике шигырьнең берсе дә совет чорындагы китапларына С. Рәмиевнең кертелмәгән ("Тәсәлла" шигыренең соңгы юллары киселеп бирелә иде). С. Рәмиевнең совет чорында басылмаган тагын бер шигыре бар: "Алар" дип атала. Шагыйрь аны Гаяз Исхакыйга һәм аның максатташ-иптәшләренә багышлый. "Алар" шигыренә эпиграф итеп һәм ахыргы сүз итеп янә Коръәннән аять алынган 48 "Җиңү" сүрәсеннән: "Мөхәммәт пәйгамбәр һәм аның белән булучылар кяферләргә карата мәрхәмәтсез, үзара яхшы мөнәсәбәттә".

Нәҗип Думави иҗатында да дини мотивлар шактый. Мәсәлән, 1928 елда язылган "Соңгы манара" шигыре:

Авырмыни сиңа "Күн!" дисең дә,
Бөтен эшләр хәзер "фәякүн"...
Ходай булгач, күз сал, кара, күр!
Ходай хәтле ходай булып торгач,
Бераз гына нигә тыймаска?!

Монда шулай ук, күрәбез, Аллага канәгатьсезлек белдерелә. Беренче ике юл дини мифологиягә ишарәли: Алла галәмне "көн!" дип әйтеп барлыкка китергән.

1916 нчы елда язган "Син — кеше!" шигыре:

Син — бөек! Салган ходай күктән сиңа үз орлыгын.
Бул — гали! Таптатма зинһар шул "ходайлык" зурлыгын!..

Ә инде "Бир яшен-тел, әй фәләк" шигырендә Н. Думави үзен Аллага тиңләп

Мин дә рәхман, мин дә каһһәр,....—

дип яза, үзенә Алла эпитетларын алып (мәрхәмәт итүче, каһәрләүче). 1912 елда "Шайтан", "Газраил яки оҗмах көткәндә", 1916 елда "Газраил" шигырьләре языла Н. Думави тарафыннан, шулай ук дини образларга таянып. "Эч поша, күңел болгана", "Син кая, әй, син кая якты өмидем йолдызы" шигырьләрендә шагыйрь Дәҗҗәл, Мәһди образларын, сират күпере, тәмугъ сүрәтләрен кертә. "Күңелемә" (1908) шигырендә күңелен сәяхәт кылып чиксез күккә, мокатдәс" "ия мәкан" (ягъни алладан) хәбәр алырга өнди.

Табигать күренешләрен тасвирлаганда да Н. Думави Коръәнгә таяна. Мәсәлән, көзне сүрәтли:

Һәммә нәрсә әллә нинди бер газап көткән кебек,
Әлхасил, җир туктаган, мәхшәр көне җиткән кебек.
*("Куркыныч", 1914)*

Ачы күзгә көнне мәхшәр белән тиңләп, куркынычлыкны арттыра. Ә инде "Бездә җәйге таң" шигыре, киресенчә, тын гына ал таң атуын, табигатьнең ямьлелеген ача безгә. Һәм янә ямьне арттырыр өчен дини сүрәт бирелә:

Гарыз итәме ушбу тынлыкта матур кош хәсрәтен,
Әллә ул тәсбих укып мактыймы алла хәзрәтен?

Монда тәсбих уку, Алланы данлау хәсрәткә каршы куела, якты сүрәт булып чыга.

Башка XX йөз башы татар шагыйрьләре Сәгыйть Сунчәләй, Шәехзадә Бабич, Мәҗит Гафури, соңрак Һ. Такташ шигырьләрендә дә дини мотивлар чагылыш таба. Ләкин шуны әйтергә кирәк, С. Рәмиев, Н. Думави, Ш. Бабич Аллага канәгатьсезлекләрен дә белдереп язсалар, ә соңрак заман сулышына ияреп М. Гафури, Һ. Такташ Алланы, Коръәнне хәттә инкарь итүгә дә җитсәләр, Тукайда без бу күренешләрне бөтенләй диярлек очратмыйбыз. "Васыятем" шигырендә Тукай яза:

Кайт, и нәфсе мөтмәиннәм! Бар, юнәл, кит тәңреңә;
Бирдең арканны моңарчы, инде бир бит әмреңә.

Дустларым, кардәшләрем, сез муллаларга әйтегез:
Бу ике юлны, мине күмгәч, укырлар кабремә.

Әһле тәкфир бер гаҗәпләнсен, күреп актык сүзем:
Күр, нә рәсмә тулган иман берле Коръән садремә!

Васыять ул кешенең үләр алдыннан әйтеп калдыра торган соңгы сүзе. Димәк, Тукай үлгәндә дә садренә иман берлә Коръән тулганын әйтергә тели.

Фикеребезне йомгаклап шуны әйтәсе килә: Тукай иҗаты, гомумән XX йөз башы татар шагыйрьләре иҗаты ислам мәдәниятеннән, Коръәннән аерылгысыз. Чөнки Коръән — ул әле яшәү рәвеше дә булган. Шагыйрьләр иҗаты күрсәтеп тора — Коръән-кәримнең авторитеты зур булган. Изге китапка таянып, шигырьләрендә аятьләр китереп, дини мифологиягә мөрәҗәгать итеп, яңа, асыл әсәрләр иҗат иткән безнең шагыйрьләребез.

## КУЛЛАНГАН ӘДӘБИЯТ


[1] Х. Миңнеголов. "Коръән" һәм татар әдәбияты // Х. Миңнеголов; Ш. Садретдинов. Әдәбият. Урта гасыр һәм XX йөз башы татар әдәбияты.— Казан, 1994.—9 нчы сыйныф.— б. 41

[2] Н. Исмәгыйль. Г. Тукай иҗатында дини һәм мифологик мотивлар // Казан утлары. 1994.— № 6.— б. 199.

[3] М. Гайнетдинов. Тукайның "адашкан" шигырьләре // Казан утлары 1991.— № 4.— б. 146.

[4] Ә. Еники. Ялганны яклау // Казан утлары.—1992.— № 4.— б. 149.